**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

БОЕРЫК | Казан ш. | ПРИКАЗ
05.09.2018 | | № 889-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибенраслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Министр урынбасарларына, структур бүлекчәләр җитәкчеләренә әлеге Тәртипнең үтәлешен тәэмин итәргә һәм аңа таянып эш итәргә.

3. Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча вазыйфаи зат катнашында кадрлар бүлеге тарафыннан башкарыла.

4.Коррупция юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә мәгълүматның һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен җаваплы.

5. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (Никулин А.Е.) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, ТР Юстиция министрлыгына җибәрергә.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр | А.В. Шадриков

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать ресурслар
министрлыгының 2018 елның 5
сентябрендәге 889-п номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгына кергән коррупция юнәлешендәге фактлар буенча
гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгына (алга таба – Министрлык) кергән коррупция һәм янап алу фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибенә карата куелган таләпләрне бозу, шулай ук Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан кылынган, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган һәм Министрлык эшчәнлеген техник тәэмин итүне гамәлгә ашыручы хезмәткәрләр (алга таба – хезмәткәрләр) тарафыннан кылынган коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели.

Башка затларга карата шундый ук фактлар турында белешмәләр булган мөрәҗәгатьләр «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль законның 8 статьясындагы 8 өлеше нигезендә мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итәргә вәкаләтле булган тиешле органга яисә тиешле вазыйфаи затка җибәрелергә тиеш.

2. Гражданинның коррупциячел юнәлештәге фактлар буенча мөрәҗәгате (алга таба — мөрәҗәгать) «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда теркәлә һәм карала.

3. Татарстан Республикасы ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасында теркәлгәннән соң мөрәҗәгать дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә, хокукый тәэмин итү бүлегенә, шулай ук коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен Министрлыкта җаваплы затка (алга таба — җаваплы зат) җибәрелә.

Кергән мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, эшләнә торган яки бөтенләй хокукка каршы эш турында, шулай ук аны әзерләүче, эшләүче яки кылган зат турында мәгълүматлар булган очракта, мондый мөрәҗәгать, вәкаләтләренә карап, хокук саклау органнарына җибәрелә.

4. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге хезмәткәргә карата билгеләнгән тәртиптә хезмәт тикшерүе үткәрә (хезмәткәрдән язмача аңлатмалар таләп ителә).

5. Хезмәт тикшерүен уздырган комиссия бәяләмәсе нигезендә коррупция күренешләре билгеләре барлыгы турында мөрәҗәгать итүдә бәян ителгән фактлар расланган очракта, министр (аның вазыйфаларын башкаручы зат) дәүләт граждан

хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы комиссиясенә күрсәтмә кертә. Хезмәткәргә карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Әгәр хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнә торган, эшләнә торган яки бөтенләй хокукка каршы гамәл, шулай ук аны әзерли торган, башкара торган яки кылган зат турында мәгълүмат булса, тиешле мәгълүмат аларның компетенциясе нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелергә тиеш.

6. Мөрәҗәгатьне юллаган гражданинга җавап әзерләү җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, шулай ук хокукый тәэмин итү бүлеге Татарстан Республикасы ведомствоара электрон документ әйләнешенең бердәм системасы ярдәмендә җаваплы затка җавап җибәрү вакыты чykканчы 15 көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итү буенча язма тәкъдимнәр җибәрә.

7. Әгәр мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата коррупция юнәлешендәге фактлар турында белешмәләр булса, соңгысы аны карап тикшерүдә катнашмый, үз ризалыгы белән катнашудан баш тарта. Мондый мөрәҗәгатьне карау дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, шулай ук Министрлыкның хокукый тәэмин итү бүлеге тарафыннан башкарыла.

8. Дәүләт хезмәткәрләрен дисциплинар җаваплылыкка тарту – «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон, хезмәткәрләрне дисциплинар җаваплылыкка тарту Россия Федерациясе Хезмәт кодексында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

9. Кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алу җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

10. Ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, җаваплы зат тарафыннан мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау үткәрелә, аларның нәтиҗәләре буенча җаваплы зат мөрәҗәгатьләрне карау буенча эш нәтиҗәләре һәм кабул ителгән чаралар, шул исәптән профилактик характердагы чаралар турында министрга (аның вазыйфаларын башкаручы затка) белешмә җибәрә.